| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
| 22 декабрь, 2014 ел | Казан ш. | № 148 |

**Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2014 елның 15 сентябрендә кабул ителгән "Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында"гы №80 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 12 апрелендә кабул ителгән "Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре" дигән №234 карары нигезендә **б о е р ы к б и р ә м:**

Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетының 2014 елның 15 сентябрендә кабул ителгән "Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат тапшыру тәртибен раслау турында"гы №80 боерыгы белән расланган Мәгълүматтан файдаланучыга аның гарызнамәсе буенча Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат тапшыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Дәүләт комитеты эшчәнлеге турында мәгълүмат – Дәүләт комитеты, аның буйсынуындагы оешмалар тарафыннан үз вәкаләтләре кысаларында булдырылган яки Дәүләт комитетына һәм аталган оешмаларга килгән Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы мәгълүмат (белешмәләр) (шул исәптән документлаштырылган) (алга таба – мәгълүмат).

Дәүләт комитеты эшчәнлеге турындагы мәгълүматка шулай ук Дәүләт комитетының һәм аның карамагындагы оешмаларның структурасын, вәкаләтләрен, формалашу тәртибен һәм эшчәнлеген билгели торган закон чыгару һәм башка төрле норматив-хокукый актлар, аларның эшчәнлегенә карый торган башка төрле мәгълүмат керә;»;

2.11 пунктының 6 пунктчасындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) гарызнамәдә Дәүләт комитеты тарафыннан кабул ителгән актларны хокукый яктан бәяләү, Дәүләт комитеты, аның буйсынуындагы оешмалар эшчәнлегенә анализ үткәрү яки гарызнамәне җибәргән мәгълүматтан файдаланучының хокукларын яклауга турыдан-туры бәйле булмаган башка аналитик эш үткәрү турында сорау куелса.».

Рәис С.Е.Иванов